# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 19 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы территориясендә теркәлгән инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Татар Карамалысы т.п. урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

2) Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;

3) Татар Карамалы т. п. Хәмитов урамы буйлап вак таш түшәү;

4) Некрологларны район газетасында урнаштырган өчен түләү;

5) Татар Карамалысы т.п. җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 237 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 171 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 171 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Татар Карамалысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, инвалидлардан, яшәүче олкәннәр (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Татар Карамалысы т.п. урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

- Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;

- Татар Карамалы т. п. Хәмитов урамы буйлап вак таш түшәү;

- Некрологларны район газетасында урнаштырган өчен түләү;

- Татар Карамалысы т.п. җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Александровка авыл җирлегенең Татар мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче

И.Ф.Вафин